ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 пунктында «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «корылмалар» сүзеннән соң «, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыклары үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалана торган җир кишәрлекләрендә төзү, реконструкцияләү һәм куллану рөхсәт ителә торган торак йортлар» сүзләрен өстәргә;

2) 14 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җир өсте су объектлары урнашкан җирләр су фонды җирләре булып тора.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр су объектлары тулысынча авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр һәм (яисә) башка категорияләрдәге җирләр чикләрендә урнашкан булса, мондый җирләр су фонды җирләренә керми.»;

3) 21 статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында «урман хуҗалыгы, урман сәнәгате, су, балык хуҗалыклары оешмалары, аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләрен «урман комплексы, су, балык, аучылык хуҗалыклары оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4) кушымтаның 2 пунктындагы 5 пунктчасының беренче абзацында «(җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясының 2 пунктындагы $3^1$ пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 63-ТРЗ